СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 1-38 «21» февраль 2020 ел

2019 елда Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2020 елга бурычлары турында

Мамадыш муниципаль районы башлыгы А.П. Ивановның 2019 елда Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2020 елга бурычлары турындагы хисабын тыңлап фикер алышканнан соң, Мамадыш муниципаль районы Советы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән булуын билгели. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү, муниципаль районның иҗтимагый-сәяси тотрыклылыгын һәм максатчан социаль-икътисадый үсешен саклап калу максатларында, Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Башлыгы А.П. Ивановның 2019 елда Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2020 елга бурычлары турындагы хисабын расларга.

2. 2019 елда Мамадыш муниципаль районы Башлыгының эшчәнлеген, Совет һәм Башкарма комитетның эшчәнлеген канәгатьләнерлек дип танырга.

3. Өченче чакырылыш Мамадыш муниципаль районы Советы депутатларына Мамадыш муниципаль районы башлыгының 2019 елда Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2020 елга бурычлар турындагы хисабын үз округларындагы сайлаучылар игътибарына җиткерергә.

4. Мамадыш муниципаль районы Советы аппаратына:

- хисап докладында һәм аның турында фикер алышканда кертелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә;

000001

- Мамадыш муниципаль районы Советының, район муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнарының даими комиссияләре утырышларының нәтиҗәлелеген арттырырга, Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре эшенең уңай тәҗрибәсен өйрәнүне һәм таратуны гамәлгә кертергә;

- Мамадыш муниципаль районы Советы утырышларында кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тотуны көчәйтергә.

5. Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетына, муниципаль районның бюджет билгеләнешләрен үтәү һәм социаль инфраструктураның нәтиҗәле эшләве зарурлыгыннан чыгып, 2020 елга түбәндәге бурычларны билгеләргә:

- 2020 елның 1 апреленә кадәр хисап докладында һәм аның турында фикер алышканда күрсәтелгән кимчелекләрне бетерү һәм тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар планын эшләргә;

- 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үсеш Стратегиясе, 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нигезендә максатчан муниципаль программалар эшләргә, Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәләре һәм төп юнәлешләре, икътисад, социаль өлкә тармакларын һәм секторларын үстерү планнары һәм фаразлары турында докладлар эшләүне гамәлгә ашырырга һәм 2020 елда Программаның төп бүлекләрен үтәүне тәэмин итәргә;

- район икътисадының динамик үсеше нигезендә инвесторларны җәлеп итү, яңа сәнәгать производстволарын оештыру буенча эшне көчәйтергә, Мамадыш муниципаль районы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен уңай шартлар тудырырга;

- район территориясендә икътисадның тотрыклы үсешен һәм социаль тотрыклылыкны тәэмин итү максатларында дәүләт, республика максатчан программалары потенциалын актив кулланырга;

- мәгариф учреждениеләренең, сәламәтлек саклау, мәдәният, физик культура һәм спорт учреждениеләренең матди-техник базасын яхшырту буенча эшне дәвам итәргә, шулай ук күрсәтелгән өлкәләрдә муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең тулы һәм сыйфатлы булуын тәэмин итәргә.

6. Мамадыш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә Мамадыш муниципаль районында бердәм финанс, бюджет сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә, бюджет проектын төзү, аны үтәүне оештыру, керемнәр буенча бюджетның планлаштырылган бурычларын үтәү, шулай ук физик затлардан, предприятиеләрдән, оешмалардан, төрле милек рәвешләрендәге учреждениеләрдән салым түләүләренең һәм җыемнарның район бюджетына үз вакытында керүен тәэмин итү буенча нәтиҗәле чаралар күрергә, вакыты чыккан кредиторлык бурычы барлыкка килүгә юл куймаска.

7. Мамадыш муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына законнар белән билгеләнгән тәртиптә 2020 елга бюджет йөкләмәсенең үтәлешен тәэмин итәргә, муниципаль милекне, шул исәптән муниципаль милектә булган җир ресурсларын район бюджетына максималь - нәтиҗәле керү буенча бюджет йөкләмәсенең үтәлешен тәэмин итәргә, күчемле һәм күчемсез муниципаль милекне куллануны контрольдә тотуны көчәйтергә, күчемсез милекнең хуҗасыз объектларын инвентаризацияләү һәм гамәлдәге законнар нигезендә исәпкә кую эшен оештырырга.

8. Мамадыш муниципаль районы Контроль-хисап палатасына муниципаль милек белән идарә итү һәм идарә итүдән алынган бюджет акчаларының максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын, бюджетка керүен контрольдә тотуны көчәйтергә.

9. Мамадыш муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә вәкиллекле органнарның ролен арттыру, Муниципаль берәмлекләр депутатлары эшчәнлегенең активлыгын арттырырга;
- авыл территорияләрен комплекслы социаль-икътисадый үстерүгә аерым игътибар бирергә;
- җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үз вакытында һәм сыйфатлы башкару буенча эшне дәвам итәргә;
- халыкның тормыш сыйфатын күтәрү максатыннан, авыл җирлекләре территориясендә гамәлгә ашырыла торган федераль, республика һәм муниципаль программаларны максималь рәвештә кулланырга;
- крестьян-фермер хуҗалыкларына һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм итү, гаилә фермалары төзү буенча республика программаларында катнашуга халыкны җәлеп итү буенча эшне активлаштырырга;
- хокук саклау органнары белән берлектә хокук бозуларны профилактикалау, терроризмга каршы тору һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның тормышын, сәламәтлеген һәм абруен ышанычлы яклауны тәэмин итү, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, авыл җирлекләре территориясендә яшәүче мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итәргә;
- торак пунктларны, күмү урыннарын төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту, җирлекләр территорияләрендә экологик иминлекне тәэмин итү эшен дәвам итәргә.

10. Мамадыш муниципаль районы Советының даими комиссияләренә утырышларда үз юнәлешләре буенча әлеге карарның 5 пунктында күрсәтелгән чараларның үтәлешен карарга.

11. Мамадыш муниципаль районы башлыгы А.П. Ивановның 2019 елда Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2020 елга бурычлары турындагы хисабын һәм докладын "Интернет" мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында(pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә .

12. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов